Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге
Арышхазда торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

16 ноябрь, 2025 ел

№ 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлегенең Арышхазда торак пунктында 2025 елның 16 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 167 (йөз алтмыш җиде).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 92 (туксан ике).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 88 (сиксән сигез).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 4 (дүрт).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Сез, 2026 елда Арышхазда торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын, көндезге уку формасы студентларын, 80 яшькә җиткән гражданнарны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Колай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Колай авыл җирлеге башлыгы — Поповская — Н.В. Поповская